# Татарстан Республикасы
# Дәүләт Советы Президиумы

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2014 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының төп чаралары планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2014 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының төп чаралары планын расларга (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2013 елның 16 октябре
№ 3124-IV ДС

C:\ДИСК C\ILSIA\PEREBOD\Sessia\2013\16 октября-президиум\3124.doc

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2013 елның 16 октябрендәге
3124-IV ДС номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәрен гамәлгә ашыру буенча 2014 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының төп чаралары планы**

| № т/б | Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасындагы тәкъдимнәр | Гамәлгә ашыру чаралары | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Без югары казанышларга ирештек һәм аннан түбәнгә төшә алмыйбыз. Республика тормышының барлык өлкәләрен дә әлеге дәрәҗәгә җиткерү бик мөһим. Булган казанышларыбыз белән бергә киләчәккә бурычларыбыз да булырга тиеш. Төгәлрәк әйтсәк – Татарстанны икътисад, инфраструктура, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм туризм өлкәсендә танылырлык итү бурычы.<br>Әлеге барлык юнәлешләрне 2030 елга кадәрге чорга Татарстан | Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәләре, комитетлар потенциалыннан социаль-икътисадый үсеш буенча актуаль проблемаларны тикшерү, дәүләт сәясәтен булдырганда һәм закон проекты эшендә гражданнарның фикерләрен исәпкә алу өчен актив файдалану | Ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары, фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Республикасының үсеш стратегиясендә чагылдыру зарур. Ахыргы максат – якын киләчәктә XXI гасырга лаеклы һәм дөнья икътисадый системасына интеграцияләнгән икътисад булдыру. | | | |
| 2. | Татарстанда соңгы елларда социаль-сәяси тотрыклылыкны саклау шартларында этноконфессиональ мөнәсәбәтләр һәм миграция сәясәте өлкәсендә җитди аңлашылмаучанлыклар килеп чыкты.<br>Нурлаттагы һәм республиканың кайбер башка районнарындагы хәлләр хакимият органнары, хокук саклау системасы һәм күзәтчелек органнары эшендә җитешсезлекләр булуны күрсәтә. | Беркетелгән сайлау округларында иҗтимагый-сәяси вәзгыять мониторингын алып бару. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайлау округларындагы эше өчен җаваплылыкны көчәйтү | Ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, комитетлары, фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре |
| | Муниципаль районнар, җирлекләр башлыкларына, хокук саклау органнарына җитди нәтиҗәләр ясарга һәм законга каршы теләсә нинди гамәлне булдырмый калдырырга кирәк. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында 2013 елның гыйнварыннан алып декабрьгә кадәр чорда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры хисабын тыңлау | 2014 елның феврале | Ш.Ш. Яһудин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Республикада Дәүләт милли сәясәте концепциясенең яңа редакциясе расланды, 2013 – 2015 елларга Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чаралар планы хупланды. Милли сәясәтнең өстенлекле юнәлешләре буенча дәүләт программалары расланды. | Экспертларның, сәяси партияләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең киң даирәсен җәлеп итеп, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр проблемалары буенча “түгәрәк өстәлләр” уздыру | Ел дәвамында | Фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары |
| 4. | Республиканың Дәүләт Советына, Хөкүмәтенә Федераль Собрание палаталары һәм Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең башкарма органнары белән үзара эшчәнлек дәрәҗәсен күтәрү зарур. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, комитетларның, Дәүләт Советы Аппаратының Россия Федерациясе субъектлары парламентлары, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе белән үзара эшчәнлеге (аерым план буенча) | Ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты |
| 5. | 2014 ел – Бөек Җиңүнең 70 еллыгына бөтенхалык бәйрәменә әзерләнү елы. Юбилей чараларын тиешле югарылыкта уздыру зарур. Бер генә ветеран да игътибарсыз калырга тиеш түгел. Әлеге мәсьәлә белән оештыру комитеты гына түгел, ә барлык хакимият органнары һәм муниципалитетлар да | “Сугыш чоры балаларына дәүләтнең социаль ярдәм чаралары турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советына “Сугыш | 2013 елның ноябре<br><br>2014 елның гыйнвары | Х.Г. Миргалимов, КПРФ фракциясе<br><br>Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шөгыльләнергә тиеш. Бу – һәр татарстанлының намус эше. | чоры балаларына дәүләтнең социаль ярдәм чаралары турында" Татарстан Республикасы законы проектын кертү | | |
| 6. | Җиңүнең 70 еллыгына әзерләнгәндә яшьләрне патриотик тәрбияләү төп максат булып тора. Үсеп килүче буынга үз иле алдында бурычлы булу һәм горурлык хисен сеңдерү мөһим. Яшьләр безнең тарихыбызны һәм батырларыбызны белергә тиеш. Сугышчылар каберлекләренә зур игътибар бирергә кирәк. | Социаль сәясәт комитетында "Яшьләрне патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбияләү турында"гы мәсьәләне карау | 2014 елның марты | С.М. Захарова |
| | Бу эштә төп җаваплылар: Татарстан Республикасы ДОСААФ, эзтабарлар оешмасы хәрәкәте, үзебезнең тарихчы галимнәребез, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары. | "Безнең яшьләребез: тарих, хәзерге көн һәм киләчәк" темасына "түгәрәк өстәл" – конференция уздыру | 2014 елның марты | Х.Г. Миргалимов, КПРФ фракциясе |
| 7. | Мөһим сәяси мәсьәләләр арасында яшьләр сәясәте игътибар үзәгендә кала бирә. Безнең балалар яңа социаль-икътисадый шартларда үсә. Мәгълүмати ачыклык яхшыдан-яхшы дөньяви практикага юнәлеш алуга китерә. | Социаль сәясәт комитеты утырышында "Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади куәтен үстерү турында"гы мәсьәләне карау | 2014 елның июне | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Безнең бурыч – яшьләрдә сәламәт акыл булдыруга көрәштә конкурентлыкка сәләтле булу. Тарихи-мәдәни мирасыбызга таянып, без үсеп килүче яшь буынның үсүе һәм аны республикада ныгыту өчен җәлеп итә торган шартлар тудырырга тиеш. Моңа Татарстан балаларының һәм яшьләренең интеллектуаль-иҗади куәтен үстерү һәм гамәлгә ашыру концепциясе ярдәм итә. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы фракцияләре һәм башка депутат берләшмәләре утырышларында яшьләр белән эшләү турында мәсьәләне карау<br><br>Яшьләр парламенты – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасының муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының яшьләр палаталары белән үзара эшчәнлеге | Ел дәвамында<br><br>Ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы фракцияләре һәм башка депутат берләшмәләре<br><br>С.М. Захарова |
| 8. | Министрлыклардагы, ведомстволардагы һәм муниципаль районнардагы иҗтимагый советлар белән уртак системалы эшчәнлеккә | Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү мәсьәләләре буенча гражданлык җәмгыяте | Ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы фракцияләре һәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күчәргә кирәк. Гражданлык җәмгыяте институтларын эзлекле үстерү, коммерциячел булмаган оешмалар инициативаларына ярдәмне арттыру һәм бу процесска бизнес җәмәгатьчелекне актив җәлеп итү мөһим. | институтлары белән хезмәттәшлек итү | | башка депутат берләшмәләре, комитетлары |
| 9. | 2014 ел Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә илебездә Мәдәният елы дип игълан ителде. Шундый ук карар Татарстан Республикасында да кабул ителде. Мәдәният – дәүләтне һәм гражданлык җәмгыятен ныгытуда иң әһәмиятле ресурсларның берсе ул. Ул – илдә барган үзгәрешләрнең рухи нигезе. Тарихи-мәдәни мирасны саклап калу һәм баету, хокукый һәм сәяси культураны камилләштерү, кешелек мөнәсәбәтләре культурасын саклау мөһим. | “Мәдәният елы кысаларында Татарстан Республикасында мәдәният өлкәсен үстерү перспективалары турында” темасына “Хөкүмәт сәгате” уздыру | 2014 елның феврале | Р.И. Вәлиев |
| 10. | Милләттәшләргә ярдәм итү – эшебезнең мөһим юнәлешләренең берсе. Татарлар, кайда гына яшәсәләр дә, Татарстанны тарихи ватаны дип саный. Шуңа күрә без телебезне, мәдәниятебезне һәм | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Бөтендөнья татар конгрессы башкарма | 2014 елның июне | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гореф-гадәтләребезне саклау өчен җаваплы.<br>“Туган телне кадерләгән халык кадерле булыр”.<br>Бу өлкәдә төп рольне Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты уйнарга тиеш. | комитеты эшчәнлеге турында”гы мәсьәләне карау | | |
| 11. | “ТНВ-Планета” телевизион каналының һәм “Ана теле” татар телен өйрәнү буенча он-лайн программасының да потенциалы зур. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Ана теле” проектын гамәлгә ашыру турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның феврале | Р.И. Вәлиев |
| 12. | Татар халкының бердәмлеген саклауга Татарстаннан читтә милли бәйрәмнәребезне үткәрү дә ярдәм итә. Беренче чиратта, бу – Сабантуй. Бәйрәм татарларның бай мәдәниятле, үзенчәлекле халык булуын күрсәтә. Хәзер Сабантуй Россиянең 55 төбәгендә һәм 23 чит илдә уздырыла. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә һәм республикадан читтә уздырыла торган Сабантуйда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының катнашуы | 2014 елның июне | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары (аерым график буенча) |
| 13. | Икътисадыбызның энергия сыешлылыгы – дөньяда иң югарылардан берсе.<br>Электр энергиясен сакчыл тоту сәясәтен яңа дәрәҗәгә күтәрү зарур. Энергиядән нәтиҗәле файдалануны | “Энергиядән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә озак сроклы максатчан программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәләре һәм перспективалары турында” | 2014 елның декабре | М.Һ. Галиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | арттыру предприятиеләрнең генә бурычы түгел, бу – безнең муниципаль берәмлекләр һәм бөтен гражданнар өчен актуаль мәсьәлә.<br>Урамнар яктыртуны реконструкцияләү һәм яңарту программасы кысаларында энергиядән нәтиҗәле файдалану мөмкинлеге бирә торган яктырткычлар һәм яктырту белән идарә итүнең заманча системаларын куллану зарур. | темасына “Хөкүмәт сәгате” уздыру | | |
| 14. | Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру хәзерге шартларда республика икътисадының конкурентлылыкка сәләтенең мөһим факторы булып тора.<br>Мондый инициативаларны актив гамәлгә ашыручы предприятиеләргә кызыксындыру чаралары булдыру һәм аларга ярдәм күрсәтү хакимият органнарының бурычы булып тора. Дәүләт преференцияләрен нәтиҗәлелекне арттыру темплары югары булган компанияләргә бирергә кирәк.<br>Моннан тыш, икътисад секторлары һәм әйдәүче предприятиеләрнең хезмәт | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты утырышында “2013 – 2016 елларга Татарстан Республикасының машиналар төзү һәм нефть химиясе комплекслары предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру” озак сроклы максатчан программасын гамәлгә ашыру барышы турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның июле | М.Һ. Галиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | җитештерүчәнлеген Россия һәм чит ил базарларындагы аналоглары белән чагыштырып бәяләү системасын булдыру зарур. | | | |
| 15. | Татарстан инновацияле бизнесны гамәлгә ашыру һәм предприятиеләр төзү өчен иң яхшы территория булырга тиеш. | “Татарстан Республикасының инновацияле мәйданчыклары потенциалын гамәлгә ашыру перспективалары” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру | 2014 елның октябре | М.Һ. Галиев |
| 16. | Икътисадый үсешнең тотрыклылыгы күп очракта реаль сектордагы кече һәм урта эшкуарлыкның үсеш дәрәҗәсенә бәйле.<br>Реаль секторда, аеруча югары технологияләр өлкәсендә бизнес белән шөгыльләнү икътисадый яктан файдалы булырга тиеш. Моның өчен гамәлдәге ярдәм күрсәтү чараларын яңадан карарга кирәк.<br>Республика районнарында индустриаль мәйданчыклар булдыру буенча муниципалитетларның эшчәнлеген көчәйтергә кирәк. | “Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү өлкәсендә дәүләт җайга салуының проблемалары һәм перспективалары” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитетының күчмә утырышында “Казан” агросәнәгать паркы” дәүләт автономияле учреждениесе эшчәнлеге турындагы | 2013 елның октябре<br><br>2013 елның IV кварталы | М.Һ. Галиев<br><br>В.П. Васильев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | мәсьәләне карау | | |
| | Бүгенге көндә агросәнәгать комплексына заманча мелиорация системалары кирәк. Авыл хуҗалыгы министрлыгына инде агымдагы елда дымлылык җитешмәү шартларында тармак үсеше стратегиясен әзерләүне йөклим. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында “Мелиорация үсешенә юнәлдерелгән чаралар (капиталь сулыкларны, сугару системаларын реконструкцияләү һәм яңарту, яңа мелиоратив объектлар төзү) турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның мае | В.П. Васильев |
| 17. | Авылларда хуҗалык итүнең гаилә фермалары рәвешендәге яңа формалары барлыкка килә. Республикада төрле юнәлештәге 908 ферма эшли, шуларның яртысы югары технологияле. Тагын 275 гаилә фермасы төзелеп килә.<br>Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итүне дәвам итәргә кирәк. Бу аз чыгымлы, әмма югары нәтиҗәле производство. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында “Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексында кече һәм урта бизнес субъектларына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның феврале | В.П. Васильев |
| | | “Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренең | 2014 елның марты | Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | проблемалары. Авыл хуҗалыгы җитештерүенең перспективалы формаларының берсе буларак коммерциячел булмаган бакчачылык ширкәтләре” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру | | |
| | Сәнәгать сәясәте һәм агросәнәгать комплексы өлкәсендәге сәясәт Россиянең Бөтендөнья сәүдә оешмасына керүенең реаль шартларыннан чыгып төзелергә тиеш. Әлеге алымны региональ үсешнең яңа моделе нигезенә салу зарур. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр комитеты утырышында “Россиянең БСОга керүе шартларында авыл хуҗалыгы продукциясе сыйфаты дәрәҗәсен күтәрү турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның июне | В.П. Васильев |
| 18. | Һәркем алырлык торак базарын булдыру, эшлекле, җитештерү һәм социаль инфраструктураны үстерү өчен шартлар тудыру зарур. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә | 2013 елның ноябре | М.Һ. Галиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ашыруны тикшереп тору комиссиясенең “Торак төзелеше үсешенә ярдәм күрсәтү турында” Федераль законның 16[6] статьясын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру турында”гы мәсьәлә буенча уртак күчмә утырышын уздыру<br><br>Торак төзелеше һәм гражданнарны торак белән тәэмин итү программаларын гамәлгә ашыруның айлык мониторингы (расланган рәвеш буенча) | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Ел дәвамында | <br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>М.Һ. Галиев |
| 19. | Торак-коммуналь хуҗалык тармагында күп кискен проблемалар бар. Бу – коммуналь челтәрләрнең искергәнлеге, технологик яктан артта калу, идарә итү системасының нәтиҗәсезлеге, шулай ук күпфатирлы йортлар ишегалларының торышы канәгатьләнерлек булмау.<br>Коммуналь челтәрләрне яңарту шәхси инвестицияләр җәлеп итүне | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт | 2014 елның мае | М.Һ. Галиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | һәм дәүләт-шәхси партнерлык инструментларын куллануны таләп итә.<br>Шул максатта, коммуналь инфраструктураның комплекслы схемаларының топологиясен, техник һәм технологик характеристикаларын күрсәтеп, бу схемаларны эшләп бетерергә кирәк.<br>Коммуналь инфраструктураны яңарту торак-коммуналь хуҗалык өлкәсенә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнарның һәм предприятиеләрнең чыгымнарын киметү мөмкинлеген бирүче заманча технологияләр кертүдән башка мөмкин түгел.<br>Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә катнаш эшләп чыгаруга, ресурсларны саклау технологияләрен файдалануга, ике контурлы казаннарны куллануга һәм тотыла торган ресурсларны исәпкә алуның заманча системаларына активрак күчәргә кирәк.<br>Ел ахырына кадәр коммуналь инфраструктураны үстерүнең махсус программасын эшләвегезне сорыйм. | программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору комиссиясенең “Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында” 2011 елның 1 августындагы 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының мониторинг нәтиҗәләрен карау турында”гы мәсьәлә буенча уртак утырышын уздыру | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20. | Узган ел ахырында Республика бәяләр сәясәте концепциясе кабул ителде. Иң якын киләчәккә төп бурыч – бишьеллык тариф җайга салуына этаплап күчү, бу хуҗалык итүче субъектларга үз эшчәнлекләрен озак вакытка планлаштырырга мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта тарифлар үсеше гомумән алганда инфляция дәрәҗәсеннән югары булмаска тиеш.<br>Тариф кампаниясе уздыру барышында инвестиция программаларының тарифларның үзгәрүенә йогынтысын да исәпкә алырга кирәк. Гавами фикер алышуны тәэмин итү зарур. Инвестиция программасын гамәлгә ашыру эксплуатация чыгымнарын киметергә һәм, ахыр чиктә, тарифлар үсеше темпларын туктатырга ярдәм итәргә тиеш. | “2014 елда коммуналь һәм торак хезмәт күрсәтүләре өлкәсендә тариф җайга салуы турында” темасына “Хөкүмәт сәгате” уздыру | 2013 елның октябре | М.Һ. Галиев |
| 21. | Ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар үз эшенең нәтиҗәсезлеге аркасында килеп чыккан өстәмә чыгымнарны ахыргы кулланучыларга кайтарып | “Идел буе федераль округында торак-коммуналь хуҗалык проблемалары турында” темасына конференция уздыру | 2013 елның ноябре | Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | калдырырга тиеш түгелләр. Тарифлар буенча дәүләт комитеты һәм муниципаль берәмлекләр моны катгый күзәтергә тиеш.<br>Халык мәнфәгатьләренә җавапсыз караган идарәче оешмаларның канәгатьләндермәслек эшенә аерым тукталырга телим. | | | |
| | Бүгенге көнгә капиталь ремонт өчен планлаштырылган сумманың өчтән бер өлеше генә җыелган; халыктан кергән акчаларны максатчан файдаланмау очраклары бар; ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар алдында бурычлар үсә; исәпкә алу сәясәте стандартлары булдырылмаган.<br>Мондый проблемаларга юл куймау максатларында Республика бердәм исәп-хисап үзәге булдыру зарур, аның эшчәнлеге электрон технологияләр нигезендә генә төзеләчәк. Барлык муниципалитетларда да түләүләрне җыюның ачыклыгын, алардан максатчан файдалануны һәм аларның хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләргә бер көн эчендә автоматик рәвештә бүленүен тәэмин | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының “Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак, коммуналь хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруны тикшереп тору комиссиясенең “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру | 2014 елның сентябре | М.Һ. Галиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | итүче система кертергә кирәк.<br>Торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын ирекле сертификацияләү системасын кертү дә дөрес булыр иде. | хакында”гы мәсьәлә буенча уртак утырышын уздыру | | |
| 22. | Соңгы елларда без өч яшьтән зуррак балаларны балалар бакчаларындагы урыннар белән тәэмин итә алдык. Әмма демографик вәзгыять әлеге мәсьәләнең элеккечә актуаль булуын күрсәтә.<br>Агымдагы елда Россиянең Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешү кысаларында мәктәпкәчә яшьтәгеләргә 5 меңнән күбрәк яңа урыннар булдырылачак. Федераль үзәк ярдәмендә өч ел эчендә 30 меңгә якын бәләкәчне балалар бакчаларында яңа урыннар белән тәэмин итү планлаштырыла.<br>Күптөрле хезмәтләр күрсәтүче балалар учреждениеләре санын арттыру максатларында шәхси инвесторларны активрак җәлеп итәргә кирәк.<br>Балалар бакчасы баланың булу урыны гына түгел. Ул республикабыз киләчәгенә нигез салучы мәгариф системасының | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның декабре | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | беренче һәм иң мөһим баскычы. Мәктәпкәчә сыйфатлы белем бирү балаларның алдагы баскычларда уңышлы үсеше һәм укуының гарантиясе булып тора. Безнең бурыч – моның өчен бөтен шартларны булдыру. | | | |
| 23. | Республика мәктәпләрен модернизацияләү дәвам итә. Киләсе елда 164 мәктәп яңартылачак. Сәләтле балалар өчен инновацион учреждениеләр челтәрен үстерүне планлаштырабыз. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф өлкәсендә дәүләт проектларын һәм программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору комиссиясенең “Сәләтле балалар өчен инновацион учреждениеләр челтәрен үстерү турында”гы мәсьәлә буенча уртак күчмә утырышын уздыру | 2014 елның апреле | Р.И. Вәлиев |
| 24. | Бүген мәгариф өлкәсе югары квалификацияле белгечләр өчен кызыксына торган өлкәгә әверелде. Агымдагы елда бу тармак хезмәткәрләренә хезмәт хакы артты. Безнең төп бурыч – мәгариф | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында “Татарстан Республикасында педагог | 2014 елның марты | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләренең эш сыйфатын аларның хезмәтенә түләү үсешенә тәңгәл рәвештә тәэмин итү.<br>Әмма хәтта иң заманча матди-техник база да белем бирү процессының үзәген – тиешле тәҗрибәгә һәм компетенциягә ия булган педагогны алмаштыра алмый.<br>Һәр укытучы һәм тәрбияче үсеп килүче буынны укытуның иң яхшы методикаларын һәм технологияләрен белергә тиеш. Татарстан бу юнәлештә актив эшли, алдынгы халыкара тәҗрибәдән файдалана. Сингапурның Educare компаниясе белән берлектә укытучыларга методик ярдәм күрсәтү системасын модернизацияләү проекты гамәлгә ашырыла. | кадрларны әзерләү һәм яңадан әзерләү турында”гы мәсьәләне карау | | |
| 25. | Игътибарны безнең муниципалитетлардагы белем бирү сыйфатында зур аерма булуына юнәлтәсе килә. Чагыштырмача тигез шартларда республиканың кайбер районнары мәгариф сыйфаты рейтингында тотрыклы рәвештә алда бара, башкалары артта калучылар рәтеннән чыга алмый. Администрация башлыкларына бу | “Татарстан Республикасында белем бирү. Проблемалар һәм перспективалар” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру | 2014 елның феврале | Х.Г. Миргалимов |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хәл турында җитди уйланырга, Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә тиешле чара күрергә вакыт. | | | |
| 26. | Республикада икътисадны модернизацияләү кадрлар квалификациясенә таләпләрне арттыра.<br>Һөнәр осталарын әзерләүнең сыйфатын беренче чиратта безнең товар җитештерүчеләр билгеләргә тиеш.<br>Кадрлар тәрбияләү эшен мәктәп эскәмиясеннән башларга кирәк. Республика сәнәгать предприятиеләренә үзләре өчен квалификацияле кадрлар әзерләүне урыннарда балаларның техник иҗаты өчен шартлар булдырып хәл итүгә аерым игътибар бирү зарур. Яңа техник иҗат үзәкләре ачу һәм инде эшләп килүче түгәрәкләрне үстерү шуңа ярдәм итәчәк.<br>Урта һөнәри белемле белгечләр-не – эшче элитаны әзерләгәндә практика өлешен көчәйтергә кирәк.<br>Икътисадның әйдәп баручы тармаклары өчен Гамәли | “Татарстан Республикасында квалификацияле эшче кадрлар әзерләү системасы турында”гы темага “Хөкүмәт сәгате” уздыру | 2014 елның мае | Р.И. Вәлиев |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | квалификация үзәкләре булдыру эшен дәвам итү зарур, алар урта гомуми белем базасында кадрларны һөнәри әзерләү үзәкләре булып торачак. | | | |
| 27. | Дәүләт Думасы тарафыннан барлык учреждениеләрнең, югары уку йортларының фәнни эшчәнлеген координацияләү буенча зур вәкаләтләргә ия Россия фәннәр академиясен реформалау турында Федераль закон кабул ителде. Бу республика Фәннәр академиясе эшчәнлегенә дә үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк. Әлеге эштән республика Мәгариф министрлыгы да читтә калмаска тиеш. | “Татарстан Республикасында академия фәнен үстерү перспективалары турында”гы темага “түгәрәк өстәл” уздыру | 2014 елның мае | Р.И. Вәлиев |
| 28. | Тармакта кадрлар кытлыгы җитди проблема булып тора. Авылда эшләргә теләгән яшь белгечләргә социаль ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәсендә 170 табиб эшкә җәлеп ителде. Ләкин бу гына җитми. Табибларның җитмәве йөкләнешне арттыра һәм медикларның эш сыйфатын киметә, чират тудыра һәм халыкның ризасызлыгын арттыра. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору комиссиясе утырышында “Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү һәм | 2013 елның ноябре | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | республика медицина учреждениеләрен квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү турында”гы мәсьәләне карау | | |
| 29. | Авыр хәлдә калган балалар аеруча игътибар таләп итә. Аларның тормышын яхшырту максатында медик-социаль тәэмин итү буенча пилот проекты гамәлгә кертелә. Балалар республика клиник хастаханәсе базасында Координацион үзәк булдырыла, анда балалар белән табиблар, социаль хезмәткәрләр, психологлар, юристлар һәм башка белгечләр эшләячәк. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору комиссиясе утырышында “Авыр хәлдә калган балаларга медик-социаль ярдәм турында”гы мәсьәләне карау | 2014 елның мае | С.М. Захарова |
| | | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының “Бердәм Россия” депутат фракциясе каршындагы “Мәрхәмәт – Милосердие” хатын-кыз депутатлар берләшмәсе утырышында халыкның аерым категорияләрен социаль яклау өлкәсендәге законнарның үтәлеше | Ел дәвамында | Ф.З. Мостафина |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | турындагы мәсьәләне карау | | |
| | | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының киңәйтелгән утырышында “Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен, шулай ук өлкәннәр һәм инвалидлар өчен учреждениеләр эшчәнлеген оештыру өлешендә законнарны гамәлгә ашыру турында”гы мәсьәләне карау | 2013 елның IV кварталы | С.М. Захарова |
| | | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының “Бердәм Россия” депутат фракциясе каршындагы “Мәрхәмәт – Милосердие” хатын-кыз депутатлар берләшмәсе утырышында “Күп балалы гаиләләрне һәм инвалид балалары булган гаиләләрне социаль яклау” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру | 2014 елның марты | Ф.З. Мостафина |
| 30. | 2013 елгы Универсиаданың гаять зур матди һәм матди булмаган | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль | 2013 елның октябре | С.М. Захарова |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | мирасын тагын бер тапкыр билгеләп үтәм. Бу еннар халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм гражданнарның сәламәтлеген ныгыту эшендә җитди этәргеч булды.<br>Бу күтәрелештә без алдыбызга физик культураның яңа идеологиясен формалаштыру бурычын куябыз.<br>Спорт – сау-сәламәт яшь буын тәрбияләүнең иң нәтиҗәле коралы. | сәясәт комитеты утырышында “Казан шәһәрендә 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге универсиадасын үткәрү йомгаклары турында һәм Универсиада мирасы концепциясен гамәлгә ашыру барышы хакында”гы мәсьәләне карау | | |
| 31. | Социаль-икътисадый үсешкә дәүләт һәм муниципаль идарәнең заманча технологияләре шактый йогынты ясый. Дәүләтнең нәтиҗәлелеген арттыруда иң кирәкле шарт – аның эшендә гражданнарның катнашу мөмкинлеге.<br>Бүген территориаль иҗтимагый үзидарәнең әһәмияте аеруча арта. Хакимият һәм халыкның нәтиҗәле партнерлыгының бу рәвешен актив үстерергә кирәк. | “Җирле үзидарә органнарының һәм халыкның актив партнерлык чарасы буларак территориаль иҗтимагый үзидарә” темасына “түгәрәк өстәл” уздыру | 2014 елның апреле | В.Н. Липужина |
| 32. | Якын арада контракт системасы турында яңа Федераль закон шартларында эшләргә әзерләнергә кирәк, ул 2014 елның 1 | “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә | 2014 елның сентябре | М.Ә. Гаделшин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | гыйнварыннан үз көченә керә. Яңа законны сынау буенча Татарстан хәзер үк Россиядә җиде пилот төбәгенең берсенә керә. Электрон рәвештәге сатып алуларны гамәлгә ашыруга, эре торглар буенча җәмәгать фикер алышуын тәэмин итүгә, сатып алуларны планлаштыру һәм анализлау тәртибен эшләүгә аеруча игътибар итәргә кирәк. | контракт системасы турында" 44-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру" темасына Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм муниципаль районнар вәкилләре катнашында "түгәрәк өстәл" уздыру | | |
| 33. | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә күп кенә хәл ителмәгән мәсьәләләр кала бирә. Коррупция хәтәре дәүләт һәм муниципаль милек белән эш иткәндә сакланып кала. Күчемсез мөлкәт объектлары белә торып дәүләт теркәвен узмый йә озак елларга түләүсез арендага бирелә. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең сакланышын тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле чаралар күрелми, ә аерым вазыйфаи затлар хәтта мондый җирләрдән файдаланалар, мәсәлән, коттедж төзелеше өчен. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру барышы хакында" комитет карарларын үтәүнең барышы турында"гы мәсьәләне карау | 2014 елның апреле | Ш.Ш. Яһудин |
| | Бюджет акчаларын үзләштергәндә | Татарстан Республикасы | 2014 елның | Ш.Ш. Яһудин |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | арадашчыларның катнашуы яисә аларны тере акчага әйләндерүче, вазыйфаи затлар белән сүз берләшкән структуралар булу вәзгыятен тамырдан үзгәртү зарур. Бу эшне, контроль оешмалар челтәрен төшереп калдырып, проектлау стадиясеннән үк башларга кирәк. Беренче чиратта бу юл һәм торак төзелешенә кагыла. | Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты утырышында "Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында" Татарстан Республикасы Законын үтәү хакында"гы мәсьәләне карау | I кварталы | |
| 34. | Дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары эшендә идарә итү сыйфатын арттыру өстенлек алырга тиеш.<br>Дәүләт аппаратын оптимальләштерү мәсьәләсенә механик яктан якын килергә ярамый. Барлык дәрәҗәләрдәге хакимият органнары үз чыгымнарына һәм функцияләренә эчке аудит үткәрергә һәм нәтиҗәле оештыру структурасын булдырырга тиеш. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты утырышында "2013 елда муниципаль берәмлекләр чикләрен үзгәртеп кору һәм үзгәртү барышының кайбер йомгаклары турында"гы мәсьәләне карау | 2014 елның феврале | В.Н. Липужина |